**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июнь № 372

г. Казань

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 294 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\372.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 13 июнь, 372 нче
карары белән расланды

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын 2017 елда тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслашу максатларында бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы акчаны түбәндәге чараларны финанслар белән тәэмин итүгә юнәлдерә:

а) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган исемлек нигезендә туберкулез микобактериясе сизгерлеген ачыклау, билгеләү һәм авыру кузгатучы күп даруларга тотрыклы булган туберкулез белән авыручы затларны дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары, шулай ук туберкулез белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибендә каралган җиһазландыру стандартлары нигезендә медицина әйберләре сатып алу;

б) кеше иммунодефициты вируслары белән (шул исәптән с В һәм (яки) С гепатитлары вируслары белән катнаш) йогышланган затларны билгеләү һәм аларны дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алу;

в) донорны медицина тикшерүе, донор органнарын алганчы аларның сакланышын тәэмин итү, донор органнарын алу, донор органнарын саклау һәм транспортлаштыру буенча чаралар һәм әлеге эшчәнлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка чаралар үткәрүне үз эченә алган, трансплантация (күчереп утырту) максатларында кешенең органнары донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеге;

г) лимфоид, кан ясалу тукымалары һәм аларга охшаш тукымаларның яман шеш авырулары, гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, таркау склероз белән авыручыларны, шулай ук органнар һәм (яки) тукымалар трансплантациясеннән соң дәвалау өчен каралган дару препаратлары белән тәэмин итүгә бәйле оештыру чараларына чыгымнар, алар үз эченә дару препаратларын саклауны, дару препаратларын даруханә оешмаларына илтеп тапшыруны, исәпкә

алуның электрон мәгълүмат базаларын төзүне һәм тәэмин итүне һәм дару препаратларының Россия Федерациясе субъектлары чикләрендә хәрәкәт итүен ала;

д) ВИЧ-инфекция һәм В һәм С гепатитларын профилактикалау чараларын тормышка ашыру, шул исәптән әлеге чараларны гамәлгә ашыруга социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларны җәлеп итеп.

5. Акчаны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәч, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндә күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында:

әлеге Тәртипнең 4 нче пунктындагы «а», «б», «г» пунктчаларында:

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру максатларында, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контрактлары төзи,

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру максатларында дәүләт контрактлары төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары шартлары нигезендә акча күчерә;

әлеге Тәртипнең 4 нче пунктындагы «в» пунктчасында:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 ел, 22 декабрь, 17-148 нче боерыгы расланган форма буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү төзи,

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә субсидия бирә;

әлеге Тәртипнең 4 нче пунктындагы «д» пунктчасында:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 ел, 22 декабрь, 17-148 нче боерыгы расланган форма буенча

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәшү буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү төзи,

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәшү буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә субсидия бирә.

8. Медицина оешмалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән формалар буенча хисаплар тапшыра:

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итүгә бирелә торган акчадан файдалану турында;

субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында.

9. Акчадан максатка ярашсыз файдалану бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

10. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәге очракларда медицина оешмаларының бирелгән акчаны өлешчә яки тулысынча кире кайтаруын тәэмин итә:

әлеге акчага ихтыяҗ булмавы (кимүе);

медицина оешмаларының дөреслеккә туры килмәгән хисаплылык тапшыруы;

медицина оешмаларының акчадан максатка ярашсыз файдалануы.

11. Медицина оешмаларына бирелгән акча әлеге Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән очракларда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән соң 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары акчаны кайтару вакытларын бозганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт чыккан көннән соң 30 көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү өчен килгән акчадан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

13. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрне тапшыра:

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан

Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килештереп раслана торган формада һәм тәртиптә субсидия аларны финанслашу максатларында бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап;

2018 елның 1 февраленә кадәр Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслый торган тәртиптә һәм формада субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында хисап.

14. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм медицина оешмаларына йөкләнә.